КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь, г.Казань № 1263

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүгә бәйле чараларны финанслау турында» 2016 ел, 27 октябрь, 790 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республики Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүгә бәйле чараларны финанслау турында» 2016 ел, 27 октябрь, 790 нчы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 2 пунктында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүгә бәйле чараларга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану кагыйдәләрендә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Министрлык квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 25 числосыннан да соңга калмыйча «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия

Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән килешүдә каралган форма һәм тәртиптә финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеге күрсәткечләре зурлыгына ирешү турында хисап тапшыра.»;

8 пунктта «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләүгә бәйле чараларга 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын әзерләү һәм үткәрү буенча башкарма оешмага субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешманың салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешма үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында түгел;»;

7 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән бурычларның булмавын раслый торган документлар;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешманың үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булмавын раслаучы документлар;»;

җиденче һәм сигезенче абзацларда «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга»;

11 пунктта «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин